| | |
|---|---|
| ГЛАВА<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО<br>ОБРАЗОВАНИЯ<br>«ШУГУРОВСКОЕ СЕЛЬСКОЕ<br>ПОСЕЛЕНИЕ»<br>ЛЕНИНОГОРСКОГО<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА<br>РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>ЛЕНИНОГОРСК<br>МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ<br>«ШӨГЕР<br>АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ»<br>МУНИЦИПАЛЬ<br>БЕРӘМЛЕГЕ<br>БАШЛЫГЫ |
| ПОСТАНОВЛЕНИЕ | КАРАР |

2023 елның 30 октябрендә №4

Лениногорск муниципаль районы Шөгер авыл җирлегенең Шөгер авылында гражданнарның үзара салым чараларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районының «Шөгер авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставының 24.1 статьясы нигезендә, Лениногорск муниципаль районы «Шөгер авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге башлыгы КАРАР БИРДЕ:

1.2023елның 18 ноябренә Лениногорск муниципаль районы Шөгер авылы җирлеге Шөгер авылында гражданнарның үзара салымы чараларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнарның җыенын 10 сәгать 00 минутка, 12 сәгать 00 минутка, 14 сәгать 00 минутка, 16 сәгать 00 минутка билгеләргә.

2.Гражданнар җыенына чыгарыла торган сорауны расларга:

Сез 2024 елда үзара салым кертүне Лениногорск муниципаль районының Шөгер авыл җирлеге Шөгер авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән, 1 төркем инвалидлардан, күп балалы гаиләләрдән (дүрт һәм аннан да күбрәк бала), Бөек Ватан сугышы ветераннарыннан, МХОдә катнашучылардан, тыл хезмәтчәннәреннән, көндезге уку формасы буенча белем алучы студентлардан тыш, һәр балигъ булган кешедән алынган средстволарны җирле әһәмияттәге түбәндәге эшләрне башкаруны хәл итүгә юнәлдерүгә 300 (өч йөз) сум күләмендә билгеләү белән килешәсезме:

2.1.торак пунктлар чикләрендә җирле әһәмияттәге автомобиль юлларына карата юл эшчәнлеге:

-Шөгер авылына Октябрь тыкрыгы, Завод, Ибраһимов, Киров, Ленин, Герцен, Тукай, Җәлил, Сәйдәшев, Гагарин, Гафиятуллин, Такташ, Почта, К. Маркс, Горький, Больничная, Павленко, Садовая, Пушкин, Халиков, П. Коммуна, Зөбәй, Габбасов тыкрыгы буенча юлларны кардан чистарту

-Вак таш белән чокыр ремонтлау, К. Маркс урамы, Җәлил урамы

-Сәйдәшев урамында асфальт белән чокыр ремонтлау

2.2.җирлек территориясен төзекләндерүне күрсәтелгән кагыйдәләргә ярашлыштырып,җирлек территориясен төзекләндерү кагыйдәләрен раслау, җирлек территориясен төзекләндерү кагыйдәләрен үтәү, инвалидлар өчен социаль, инженерлык һәм транспорт инфраструктурасы объектларына һәм күрсәтелә торган хезмәтләргә ирешү мөмкинлеген тәэмин итү таләпләрен үтәү,:

- Шөгер авылында Завод, Ибраһимов, Киров, Ленин, Герцен, Тукай, Җәлил Сәйдәшев, Гагарин, Гафиятуллин, Такташ, почта, Маркс, Горький, Больничная, Павленко, Садовая, Пушкин, Халиков, Коммуна, Зөбәй, Габбасов тыкрыгы, Такташ урамнары,Октябрь тыкрынгында урамнарны яктыртуны ремонтлау һәм техник хезмәт күрсәтү
-Берьеллык чәчәкләр алу
-Парк эскәмияләрен сатып алу
-Урналар сатып алу
-Габбасов тыкрыгында авария хәлендәге агачларны кисү

2.3.торак пункт чикләрендә халыкны су белән тәэмин итүне, су чыгаруны, халыкны ягулык белән тәэмин итүне Россия Федерациясе законнары белән билгеләнгән вәкаләтләр чикләрендә оештыру
- Шөгер авылында су белән тәэмин итү челтәрләрен ремонтлау һәм төзү.
2.4. халыкның күпләп ял итү урыннарын (парклар, скверлар, яр буйлары, пляжлар, спорт мәйданчыклары һәм халыкның башка күпләп ял итү урыннарын) төзү, ремонтлау һәм аларга якын территорияне төзекләндерү:
-стадионда һәм авыл паркында «Юность» үлән чабу

«РИЗА» «КАРШЫ».

3. Әлеге карарны түбәндәге адрес буенча урнашкан мәгълүмат стендларында халыкка җиткерергә: Татарстан Республикасы, Лениногорск районы, Шөгер авылы, Киров ур., 17 йорт административ бина, Киров ур., 23 йорт, «ЛТС» ҖЧҖ - Ленин урамындагы 3 нче Энергорайон, Ленин урамы, 32 йорт, Шөгер авылы мәдәният йорты, Ленин урамы, 35 йорт, Шөгер участоок хастаханәсе, Горький урамы, 4 йорт адресы, Лениногорск муниципаль районының рәсми сайтында (http://leninogorsk.tatarstan.ru) «Авыл җирлекләре» бүлегендә һәм Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында (https://pravo.tatarstan.ru/) бастырырга.
4. Әлеге карар басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Лениногорск муниципаль районы
«Шөгер авыл җирлеге»
муниципаль берәмлеге башлыгы Р.Н.Гафиятуллин